








## ТАССРга - 100 ел

### *Яшә, Республикам!*

***Татар халык җыры****

Биек тауның башларында
Уйный каплан баласы;
Яшә, минем республикам,
Яшә, Казан каласы!

Аккошлар чума күлләргә,
Былбыл куна гөлләргә;
Җырлый-җырлый без барабыз
Алдагы шат көннәргә.

Безнең илләр ямьле җирләр,
Үсә бездә ал гөлләр;
Гөлләр кебек матурланды
Безнең хәзерге көннәр.

***** *Әлеге җырга - 100 ел! Ул ТАССР оешкан мәлдә - 1920 елда иҗат ителгән.***

**“КЫЗЛАР ИЛЕ” ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ**

**Безнең адрес:** Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәскәү районы, Декабристлар урамы, 89 А.

**E-mail: kzlar_ile@mail.ru**

**Шеф-мөхәррир:**
Зөммәрәт Шамил кызы НӘГЫЙМОВА

**Баш мөхәррир:**
Рәмилә Гамил кызы ГАЗИЗУЛЛИНА

**РЕДКОЛЛЕГИЯ**
Зилә ХӘБИБУЛЛИНА
Ләйлә ЙОСЫФОВА
Камилә ГОБӘЙДУЛЛИНА
Сөмбел ФАТЫЙХОВА
Җәмилә ҖӘЛИЛОВА
**Чыгарылыш өчен җаваплы:**
“Нур” балалар оешмасы

***Зыялы кыз — ил күрке!***

# КЫЗЛАР ИЛЕ

**Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназиянең «Нур» балалар оешмасы газетасы**

**2012 елның февраль аеннан чыга**

**6 +**

**№ 8 (9)**
**сентябрь-декабрь**
**2019 ел**

## Бүгенге санда:

- ***“Ин-ин УКЫТУЧЫ”*** *2-3 битләр*
- ***“Ак яулыклы әү әнием - 2019”*** *4 бит*
- ***ЙолаФест*** *5 бит*
- ***Гаилә Фестивале*** *5 бит*
- ***WorldSkills Kazan 2019*** *6-7 битләр*
- ***“Нур” балалар иҗтимагый оешмасы: “Без - Республикабыз киләчәге!*** *8 бит*
- ***“Белем ярминкәсе”*** *9 бит*
- ***Гаиләмнең Җиһу таңнары*** *10-11 битләр*
- ***ТАССР җыры*** *12 бит*



***2020 ел - Россиядә Хәтер елы***

***“Җәлил кебек бөек исемнәрне атаганда, изге сүзләрне әйткәндә, уйланып торырга иде, җаныбызны, күңелебезне чистартып алырга иде...”***

***Туфан Миңнуллин***

Укытучы! Кем генә уйлап чыгарган бу тылсымлы сүзне. Укытучы - миңа икенче ана. Һәр көнемне мин алар белән үткәрәм. Алар миңа белем бирә, кирәк чакта мин алардан киңәш сорыйм.

Күренекле шагыйрь Фәнис Яруллин да болай язган:

***Килгән чакта башка авырлык,***
***Житми калса көч йә сабырлык,***
***Сездермичә ярдәм иткәнсез —***
***Сез иң күркәм кеше икәнсез.***

Минемчә, укытучы булырга бик авыр. Ул сабыр, тырыш, көчле булырга тиеш. Шуңа да без УКЫТУЧЫЛАРЫБЫЗ алдында баш иябез!

Без, гимназия хәбәрчеләре, узган уку елы дәвамында укучылар арасында "Иң-иң УКЫТУЧЫ" дип исемләнгән сораштыру уздырдык. Хезмәтебезнең кайбер нәтиҗәләре - бирелә! Форсаттан файдаланып, укытучыларыбызның балачак хыяллары белән дә кызыксындык. Рәхмәт сезгә, кадерле остазларыбыз!

***Сөмбел ФАТЫЙХОВА, хәбәрче.***



## СӨЙКЕМЛЕ УКЫТУЧЫ

***Әхмәтвәлиева Ләйлә Рафаэлевна, математика укытучысы***

**Балачакта кем буласыгыз килде?**
- Юрист.

**Сезнең балачак хыялыгыз?**
- Диңгезне күрү.

**Мәктәптә яраткан фәннәрегез?**
- Тарих, җәмгыять белеме.

**Яраткан бәйрәмнәрегез?**
- Яңа ел.

**XXI гасыр укучысы ул...**
- Актив, заманча... киләчәккә максаты булган шәхес!

## ЗИРӘК УКЫТУЧЫ

***Нәҗметдинов Наил Мәхмүт улы, физика укытучысы***

**Балачакта кем буласыгыз килде?**
- Очучы!

**Сезнең балачак хыялыгыз?**
- Мәктәп директоры буларга һәм һәрвакыт суыткычта лимонад булуын тели идем.

**Яраткан фәннәрегез?**
- Физика минем иң яраткан дәресем иде.

**Яраткан бәйрәмнәрегез?**
- Мин 1 май бәйрәмен яратам.

**XXI гасыр укучысы ул...**
- Ул ярдәмчел, шәфкатьле булырга тиеш.

## АКЫЛЛЫ УКЫТУЧЫ

***Шагеева Светлана Вячиславовна, рус теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Балачакта кем буласыгыз килде?**
- Минем укытучы буласым килде.

**Сезнең балачак хыялыгыз?**
- Балачакта минем диңгездә буласым килде, ул хыялым тормышка ашты.

**Яраткан фәннәрегез?**
- Алар күп иде: рус теле, рус әдәбияты, география, инглиз теле һәм физкультура.

**Яраткан бәйрәмнәрегез?**
- Минем яраткан бәйрәмем - Яңа ел.

**XXI гасыр укучысы ул...**
- Минем уйлавымча, ул бала матур сөйләшергә, үзенә бәя бирә белергә, теләсә нинди сорауга җавап бирергә, авыр хәлдә теләсә нинди кыенлыктан чыгу юлын табарга тиеш.



## ЭШЛЕКЛЕ УКЫТУЧЫ

***Вәлиева Мәйсәрә Насртдиновна, милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары***

**Балачакта кем буласыгыз килде?**
- Тәрбияче буласым килде.

**Сезнең балачак хыялыгыз?**
- Машина йөртергә хыялландым.

**Мәктәптә яраткан фәннәрегез?**
- Алгебра.

**Яраткан бәйрәмнәрегез?**
- Бәйрәмнәрне яратмыйм.

**XXI гасыр укучысы ул...**
- Кеше буларак, ЧЫН КЕШЕ булырга тиеш!

## САБЫР УКЫТУЧЫ

***Сәмитова Альмира Миңнуровна, башлангыч сыйныфлар укытучысы***

**Балачакта кем буласыгыз килде?**
- Кечкенәдән укытучы булырга теләдем.

**Сезнең балачак хыялыгыз?**
- Космоска очу.

**Мәктәптә яраткан фәннәрегез?**
- География.

**Яраткан бәйрәмнәрегез?**
- 8 март бәйрәме.

**XXI гасыр укучысы ул...**
- Ул бар яктан да килгән. Креатив..



## ЮМАРТ УКЫТУЧЫ

***Талипова Сәрия Әмир кызы, рус теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Балачакта кем буласыгыз килде?**
- Мин кечкенәдән үк укытучы буларга хыялландым. Бүлмәдә курчакларымны тезеп куя идем, нәрсәдер яздырган булам. Кайвакытта указка тотып, аларны ачуланган була идем... Дәү әни аптырап, ишекне ачып карый иде, мине кем белән сөйләшә икән дип.

**Балачак хыялыгыз?**
- Балачак хыялым - укытучы булып, дәфтәр тикшерү иде. Тормышка ашты!

**Яраткан фәннәрегез?**
- Мәктәптә иң яраткан фәннәрдән математика, инглиз теле һәм химия иде. Математикадан сыйныфташлардан ике-өч темага алдан бара идем.

**Сезнең яраткан бәйрәмнәрегез?**
- Яраткан бәйрәмнәрдән - Яңа ел. Нишләптер, Яңа ел яңа өметләр алып килер төсле иде...

**XXI гасыр укучысы ул...**
- Һәрнәрсәгә җитез, төрле яктан укымышлы кеше; үз максатына ирешүчән яхшы белгеч.

## ИҖАДИ УКЫТУЧЫ

***Насыйбуллина Гөлнур Зәкәриевна, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Балачакта кем буласыгыз килде?**
- Укытучы булырга теләдем һәм булдым.

**Сезнең балачак хыялыгыз?**
- Институтка укырга керү, белемле булу, гаилә булдыру.

**Мәктәптә яраткан фәннәрегез?**
- Тарих, әдәбият, музыка.

**Яраткан бәйрәмнәрегез?**
- Әниләр бәйрәме.

**XXI гасыр укучысы ул...**
- Креатив, булдыклы, фикерле, заманча шәхес...

***Рамина ЮРОВА, Дина ГАЙНУЛЛИНА, Ләйлә ЙОСЫФОВА, Камилә КАСЫЙМОВА, Камилә ГАБДРАХМАНОВА сораштырды.***

# Ил аклыгы - дәү әниләр



1 октябрь - Халыкара Өлкәннәр көне. Бу көнне без дәү әниләребезне гимназиягә кунакка чакырабыз. Ел саен Актлар залында алар өчен “Ил аклыгы - дәү әниләр” бәйгесе уздырыла. Әйтергә кирәк, бу бәйге гимназиядә быел бишенче тапкыр оештырылды. Бәйгенең төп максаты - буыннар чылбырын саклау. Бирәдә оныкчыклар дәү әниләре белән катнаша. Бәйгедә катнашучылар “Тормыштагы биш бәхетле мизгел”, “Гаилә ядкәре”, “Сәләт”, “Татлы бүләк”, “Дәү әнидән кучтәнәч” кебек номинацияләрдә көч сынаша.

Быел бәйгебездә дәү әниләр Казан шәһәреннән генә түгел, ә Балык Бистәсе, Арча, Апас, Кукмара районнарыннан ук килделәр. Дәү әниләргә гимназия музейлары буенча экскурсия уткәрелде, ахырда үз кучтәнәчләре белән чәй табыны әзерләнде. Бәйгенең тагын бер үзенчәлеге - монда татар дәү әниләре генә түгел, башка милләт дәү әниләре дә бик теләп катнаша. Шундыйларның берсе - Оморова Ульяна Николаевна. Ул үз гаиләсенең бәхетле мизгелләре, кадерле ядкәрләре турында рус телендә сөйләр.

***Җәмилә ҖӘЛИЛОВА,***
***6 А сыйныфы укучысы.***

Я, Оморова Ульяна Николаевна, - бабушка Амуланги Дорджиевой, ученицы 4 Б класса, мама троих детей и бабушка 4х внуков. Приехала в конце 70х, училась в Казанском Институте Культуры и Искусства, по специальности библиограф-искусствовед. Приехала из Калмыкии, Калмычка по национальности. Муж учился в КАИ, авиационном институте, киргиз по национальности. На протяжении многих лет, почти сорок лет, сохраняются уважение и любовь к моим киргизским родственникам. Моя свекровь – бывшая балерина, свекор – бывший офицер, выпускник Могилевской школы КГБ, именно они очень бережно, интеллигентно прививали любовь к киргизским обычаям, языку, культуре.

Моя старшая дочь, закончила КГУ, филолог по образованию, но нашла себя и работает в индустрии красоты. Амуланга, ее дочь. Моя старшая внучка. Амуланга - в переводе с калмыцкого означает «счастье», «процветание». Моя вторая дочь – Наргиза, выпускница Казанского Энергетического Университета, кандидат политических наук. Преподавала в Казанском Энергетическом Университете, работала научным сотрудником Института истории имени Ш.Марджани в Кремле, сейчас в отпуске с малышом, моим внуком Кириллом. Муж моей дочери Наргизы – Никита. Русский по отцу и по матери. На половину татарин, и поляк по одной из его бабушек. Внук Кирилл православный, его крестили в церкви, таково было решение его родителей. И я, как бабушка, с большим уважением приняла и согласилась. Мой сын – Алмаз, учился в КХТИ. его жена – Гельсина, татарочка. У него две девочки Марьям и Малика, моя мусульманская семья и мои внучки – мусульманочки.

У меня очень интернациональная семья, где дружно с любовью и уважением живут и буддисты, и православные, и мусульмане. И это очень здорово!

Семейные реликвии нашей семьи: киргизско-русский словарь 1944 года и национальный сувенир в виде плётки – Камча. Уникальный словарь был подарен мне моим свёкром в Киргизии. Этому изданию 75 лет… Камча – символ хозяина в доме, порядка, достатка, послушания. Переходит от отца к сыну по мужской линии, хранится в доме на самом видном месте.

***Ульяна Николаевна ОМОРОВА.***



# Без - 12 нче гимназия гаиләсе!









Гимназия тормышы - үзе бер гаҗәеп дөнья! Уку йортыбызда ел саен ике-өч Фестиваль уздырыла. Гимназиянең туган көнендә тәүге мәртәбә Татар халкы йолалары Фестивале - ***ЙолаФест*** уткәрелгән булса, 29 ноябрьдә барлык сыйныфлар ***Гаилә Фестивалендә*** катнашты. Әлбәттә, бик тиздән - 21 февральдә инде дүртенче тапкыр ***Халыклар дуслыгы Фестивале*** уздырылачак. Ул быел ТАССРның 100 еллыгына багышлана.

**ЙОЛАФЕСТ** - ул татар халкының борынгы йола-бәйрәмнәрен өйрәнүгә һәм барлауга багышланган чара. Ул быел нәкъ гимназиябезнең туган көнендә - 29 октябрьдә оештырылды. Ни өчен 29 октябрь дисәгез, җавабы - бик мәгънәле, тарихи. 1916 елның 29 октябрендә мәшһүр мөгаллимә, җәмәгать эшлеклесе Фатиха Габделвәли кызы Аитова Казан шәһәрендә беренче кызлар гимназиясе ачкан. Әлеге күркәм вакыйганы истә тотып, без һәр ел бу көндә Гимназия көнен билгеләп үтәбез.

ЙолаФест быел, чыннан да, бик тә кызыклы, җанлы, дустанә мохиттә узды. Бирәдә 2-11 сыйныф укучылары әзерләгән Сөмбелә, Каз өмәсе, Нардуган, Нәүрүз, Карга боткасы, Сабантуй бәйрәмнәрен, Кунак каршы алу, Исем кушу, Бәби чәе, Бишек җыры, Орлык чыгару, Яңгыр теләү, Басу, бураӡна яру, Бирнә әзерләү, Туй йолаларын тамаша кылдык. Бәйрәмебезгә нур һәм куәт өстәп, гимназия директоры Зөммәрәт Шамил кызы Нәгыймова белән күренекле драматург Туфан аганың кызы Әлфия ханым Юнысова-Миңнуллина безгә - укучыларга изге теләкләрен юллады. Күркәм Фестиваль гимназия гимны белән тәмамланды. Туфан ага әйтмешли, 10 Әлмәндәр гомере телим сиңа, ГИМНАЗИЯМ!

**ГАИЛӘ ФЕСТИВАЛЕ** - “Укучы - Сыйныф җитәкчесе - Әти-әни” бәйләнешен ныгытучы Фестивальләрнең берсе. Бирәдә укучылар әти-әниләре, әби-бабалары һәм сыйныф җитәкчеләре белән бер сәхнәдә катнашты. Шулай ук һәр сыйныф “Минем гаиләм - Бөек Җину тарихында” темасына багышланган күргәзмәне оештыруда да үз өлешен кертте. Чыннан да, безнең гимназиябез - зур, бердәм,









тату бер гаилә. Без бергә - бер йодрык, без бергә - бер дәүләт! Без - 12 нче гимназия гаиләсе!

Халыклар Дуслыгы Фестивалендә очрашканга кадәр, дуслар!

***Сөмбел ФАТЫЙХОВА,***
***6 А сыйныфы укучысы.***

# Welcome to Kazan!

Благодаря различным международным чемпионатам и соревнованиям, проводимых в нашем городе, Казань узнают во всех уголках мира. Прекрасная Казань с удовольствием встречает и принимает гостей с разных стран. Вот и в этом году наша столица удостоилась чести провести на своей территории 45-й чемпионат мира по профессиональному мастерству WorldSkills Kazan 2019.

Гостей знакомили с историей Казани, проводили экскурсии по музеям Кремля, угощали национальными блюдами. Некоторым школам представилось возможность принять у себя команду из определенной страны. Наша гимназия была в числе тех, к кому приехали зарубежные гости. Мы встречали делегацию из Марокко. Марокканцев встретили зажигательными танцами и песнями. Девочки-кураистки исполнили татарские народные мотивы. В наших музеях гостям рассказали историю нашей гимназии и о нашем любимом Туфане Миннуллине. В сортивном зале провели игровую эстафету, в которой победила Дружба. В кабинете кулинарии девочки научили гостей готовить кош теле – хворост, который им очень понравился.









В свою очередь, марокканцы продемонстрировали видеоролик о своих профессиях, которые представили на WorldSkills. Делегаты участвовали в таких компетенциях, как кондитерское дело, мехатроника, электромонтаж, обслуживание тяжелой техники.




В конце душевной встречи мы все обменялись памятными подарками. Гостям из Марокко очень понравилась наша красивая гимназия. Она стала частью WorldSkills. Так же марокканцам полюбилась и Казань. Все они пообещали, что при любой возможности обязательно приедут к нам снова. А Казань всегда будет всем рада. Welcome to Kazan! Казанга рәхим итегез!

*Лилия НАЗМИЕВА,*
*ученица 9 А класса.*



# Добро пожаловать в Казань!

25 августа нашей гимназии удалось стать участницей Всемирно известного чемпионата по рабочим профессиям – Worldskills Championship 2019 Kazan в рамках программы «Одна школа – одна страна». Мы были очень рады нашим гостям – делегации из Марокко. Встречала и принимала делегацию администрация гимназии во главе с директором Нагимовой Зуммарат Шамиловной, завучами и гидами-переводчиками - Шайхутдиновой Альбиной Рафисовной и Хрипковой Дианой Игоревной.

В масштабном мероприятии принимали участие





ученицы и учителя гимназии.



Наша встреча началась с очень красочного и интересного концерта во дворе гимназии; тут были и певцы, и танцоры, и кураисты. Концерт задал нужный тон и настроение для наших гостей. Хочется отметить, что сами гости были очень дружелюбно настроены, с интересом и с большим желанием принимали участие во всех мероприятиях, а их было очень много. Например, сразу же при входе гостям свои силы и поучаствовать в таких состязаниях, как перетягивание каната, армрестлинг, прыжки в мешках. Далее ученицы гимназии подробно рассказали о музеях нашей гимназии.

Учителя музыки научили наших гостей играть известную татарскую мелодию «Суда-суда» на курае. Гости познакомились с национальными блюдами Татарстана, посетили наш кулинарный класс, а также творческую мастерскую, где девочки представили свои поделки, ручные работы, платья, картины и многое другое.

После делегация познакомила наших учениц с чемпионатом и со своими рабочими профессиями. Беседа проходила на английском языке легко, увлекательно и интересно. После презентации гостей ученицы смогли пообщаться с делегацией, задавали интересные вопросы. На память мы сделали фотографии об этом незабываемом дне.

Это удивительное и захватывающее событие для нашей гимназии, которое надолго запомнится нам всем!

***Альбина Рафисовна ШАЙХУТДИНОВА,***
***Диана Игоревна ХРИПКОВА,***
***учителя английского языка.***

# МЫ - БУДУЩЕЕ РЕСПУБЛИКИ!

Как много в мире знаков, и как редко мы обращаем на них внимание. Знаки дорожного движения, знаки социальных сетей, магазинов и даже знаки наших любимых и родных организаций. Для меня это не просто знаки и символы. В них есть что-то таинственное и очень важное для меня.



Я - Хабибуллина Зиля. С малых лет занимаюсь музыкой. Для меня музыка - это знак скрипичного ключа, который определяет расположение нот на нотном стане. Также я являюсь ведущей детского телеканала “ШаянТВ”. У него тоже есть свой знак - эмблема канала. Шаян - это значит “озорной”.

Большую часть моего времени я посвящаю общественной деятельности. Стараюсь помогать везде и во всем. Хочу выделить 3 самых близких мне организаций: городская организация “Дети Казани”, республиканская организация “Совет детских общественных организаций РТ” и самая любимая школьная детская общественная организация “Нур”.

Знак “ДК” - это две заглавные буквы, которые объединяют всех активистов города Казани.

Знак “СДО” - это две руки, тянущиеся в верх, к звездам. Это самые яркие активисты нашей республики.

Значком ДОО “Нур” является розовый тюльпан с зелеными лепестками. Лепестки тюльпана олицетворяют дружбу всех, кто входит в организацию, невзирая на возраст и разные интересы. Организацию “Нур” я тоже представляю в знаках. СМИ - это знак инстаграмма. Наш аккаунт живет очень яркой и информативной жизнью. Знаки валюты, рубля и доллара - волонтерская деятельность. Как же хорошо, когда можно поделиться чем-то полезным, для кого это, действительно, важно. Мы бережем природу, работаем в экологическом направлении. Знак этого направления - росток, который только-только начинает свою жизнь. Знак патриотического направления - это татарский орнамент. Мы гордимся нашим народом и не забываем наши традиции.

Самое важное направление нашей организации - это работа с детьми-сиротами и детьми с ОВЗ. Знаком данного направления являемся МЫ - ДЕТИ!

МЫ - БУДУЩЕЕ нашей РЕСПУБЛИКИ!

***Зиля ХАБИБУЛЛИНА,***
***президент ДОО “Нур”,***
***победитель конкурса “Лидер года - 2019” в номинации “Будущее Республики”.***



# ЯРМАРКА ИДЕЙ - ЯРМАРКА ЗНАНИЙ



В нашей гимназии совсем недавно появилась традиция проводить Ярмарку Знаний. Каждый год старшие и младшие классы готовят интересное научное выступление, приносят с собой животных и показывают разные опыты.

На ярмарке можно встретить 3D принтер, который может распечатать любую фигуру, очки виртуальной реальности, с помощью которых ты погружаешься в иное измерение. Конкурсы, в которых можно сделать что-то своими руками, а после забрать это домой. Интересные эстафеты и соревнования в скорости и твоей ловкости. За каждый выигрыш можно получить хоть и маленький, но приз. На ярмарку иногда приносят наших братьев меньших: крыс, хомяков, даже попугаев.









“Ярмарка Знаний - 2019” среди 5-11 классов состоялась в марте нынешнего года, среди 1-4 классов - 7 декабря. Ждём новые идеи и до встречи на “Ярмарке Знаний” в 2020 году!





***Камиля ГУБАЙДУЛЛИНА,***
***ученица 6 А класса.***

# Фронтовик истәлекләре

Бөек Ватан сугышында минем кадерле Баһау бабам катнашкан. Бүген мин сезгә бабам мисалында татар халкының бөеклеген күрсәтәсем килә.

Сугышта булган вакыйгаларны бабай еш искә ала иде. Стройда барганда: “Раз, два, три!” дип, маршировать иткәндә дә, стройда да ул һәрчак кычкырып: “Йә Аллаһы! Йә Рахман! Йә Рахим!” – дип җырлаган. “Син нәрсә җырлыйсың, Баһау?!” – дип сорагач, менә мин әйткән сүзләрне кабатласагыз, барыгыз да исән-сау туган якларыгызга кайтырсыз, ышаныгыз”, - дип җавап бирә. Өметсез – шайтан гына, диләр. Үлем кочагына, үлем утына кергән солдатларда әле өмет чаткысы сүнмәгән. Бабайның сүзләре аларда янә яшәү өмете уята.

1943 елда бер машина тулы снарядны сугыш кырына илтәләр. Төнлә күз ачып булмаслык күзгә караңгылык. Ут кабызырга ярамый, чөнки өстән приказ, немец разведчиклары күрүе ихтимал. Шулай юлдан бара торган машина кинәт кырыйга төшеп китә дә каплана, машинага ут каба. Ни гаҗәп, бабай артыннан шул догаларны укыган иптәшләре бары тик тән җәрәхәтләре генә ала. Барысы да исән-имин шушы котычкыч бәладән котылалалар. Бабай бу хакта үзенең көндәлегенә язып калдыра. Бу вакытта аның кул бармаклары сына, азрак госпитальдә ятып, 50 яше тулгач, демобилизацияләп, кайтарып җибәрәләр. “Бу урыс, поляк солдатларының мин киткәч тә Ислам диненә күчүенә шигем юк”, - дип теркәп куйган бабам үзенең язмаларында.

Алар Австрия, Польша солдатлары белән бик дус булалар. Бабай сугышта элемтәче булып хезмәт итә. “Мин яткан урыннан торып китәм генә, фашист снарядлары шул урынга төшеп, 3-4 метрлы чокыр хасил була. Кабат яткан урынымнан кузгалам гына, тагын шул күренеш. Иптәшләрем шаккатып: “Үлемсез Баһау син! Синең тирәдә генә йөрергә кирәк”, - дип, шаяртып та алалар иде. Шулай да сугыш үзенең тирән ярасын бабайга салырга өлгерә...

Бабам, сезгә якты дөнья өчен мең рәхмәт!

***Зәйнәп ЗАРИПОВА,***
***8 Б сыйныфы укучысы.***

Мой дедушка, Хабибуллин Фазыл Музгирович, военный летчик подполковник, Ветеран вооруженных сил. Он награжден множеством орденов и медалей.

Военный летчик - это героическая профессия. Быть летчиком может не каждый, это дано только сильным духом и смелым людям. И таким был мой дедушка, уроженец деревни Бик-Утеево Буинского района Татарской АССР.

В жизни легких дорог не бывает... Окончив школу, в 1963 году дедушка Фазыл поступил в Ульяновский аэроклуб, а после его окончания - в Армавирское высшее военное училище летчиков.

После завершения обучения в лётном училище, дедушка Фазыл был направлен летать на Дальний Восток. Там он летал на сверхзвуковых истребителях, охраняя воздушные рубежи нашей Родины.

Затем дедушка поступил учиться в Военно-воздушную академию имени Гагарина в Москве. Был участником парадов на Красной Площади, за что имеет поощрения от Главнокомандующего Вооруженных сил.

После окончания академии, дедушка Фазыл был направлен командиром истребительской авиационной эскадрильи в Брянский корпус.

В Ставропольском летном училище в течение 15 лет он учил молодых летчиков воздушному бою, передавая свой богатый опыт.

В 1992 году дедушка ушел в отставку и в этом же году со своей семьей вернулся на родину - в Республику Татарстан.

Находясь на заслуженном отдыхе, дедушка преподавал военное дело в татарско-турецком лицее для мальчиков в г.Казани.

Его не стало уже в 58 лет, наверное, сказались тяготы военной службы. Мы храним светлую память о нем. Его помнят и сослуживцы как человека справедливого, стойкого и жизне-любивого, отдавшего свою жизнь и здоровье службе Родине.

***Камиля ГУБАЙДУЛЛИНА,***
***ученица 6 А класса.***



# Әтиемнең әбисе – Чиста Галимә!

Азат бабамның сөйләгәннәре буенча аның әнисе Шакир кызы Галимә 1911 елда туган. Әтисе 1914 елда ук салкын тиеп үлеп китә. Узган гасырның 20-нче елларда Ядегәр авылында “Кызыл бүрекче” дигән артель төзелеп, ул шунда эшкә керергә ниятли. Әмма яше җитмәгәнлектән, ул авылның мулласыннан үтенеп сорап, үзенең 1908 елда туганлыгы турында белешмә юнәтә. “13 яшьтә эшли башладым” – диюен караганда бу 1924 елга туры килә. Әбием Галимә, аның әнисе Гыйльмиҗамал һәм Галимә әбинең апасы Минниса бергә яшәп ятканда Минниса туганнары Минһаҗ бабайга ияреп Оренбургка китә һәм шунда кияүгә чыга. Галимә әби эшкә бик таза була. Мех калдыкларыннан бүрек җүрмәү белән бергә 30-нчы елларда оештырылган “Субаш” колхозында кыр эшләрендә катнаша. Яхшы нилэгәнгәдер инде, бер елны Казанга колхозчылар съездына делегат булып җибәрәләр. Шунда беренче мәртәбә циркка бара. Чая кыз булгандыр, укытучы, авыл активисты, биючe егет Фатыйхка кияүгә чыга. 1938 елда кызлары Люция (ул апа әле дә исән-сау), 1941 елда уллары Рөстәм туа.

Сугыш чыккач, Галимә әби ике бала белән тылда кала. Артель сугышчылар өчен бүрек-бияләйләр тегә, чималны - мех калдыкларын Казан мех фабрикасыннан күтәреп ташыйлар. Бернинди транспорт бирелмәгән. Алар артельдә эшләүче башка хатын-кызлар белән бергә ничек кирәк шулай әрсезләнеп тимер юл вагоннарына утырып Казаннан Шәмәрдән станциясен кадәр әллә нинди маҗаралар белән кайталар. Бабаем Азат сөйләвенчә, берсендә аны мех калдыкларын җыйнап төягән зур гына төрчәген тимер юл вагонында кайтканда талый башлыйлар. Әбием төрәгенә чытырдап ябыша – артельгә алып кайтып җиткермәсә җавапка тартулары бар бит! Ачуы чыккан шпана бармаклары арасына кыстырган лезвие белән әбинен битен яра. Әби барыбер ычкындырмый йөген, бөтен көчен шпананың пычрак кулына тешләрен батыра. Йөген саклап кала, әмма битендә җөе бик озак күренеп торган икән.

Тормыш ифрат авыр булса да, Галимә әбине үҗәт тырышлыгы, бернинди эштән курыкмавы коткарган. “Артельгә!” дип, өендә бүрек теккән. Аны Казанга алып барып, я юлда саткан да әнисенә, балаларына азык юнәткән. Сугыш елларында аларга фатирга Украинадан килгән ике хатынны, Ядегәр участок хастахнсендә эшләүче табиб Чекменева дигән хатынны керткәннәр. Әле тагын НКВД кешесе Сәләхиев исемле куркыныч зат та, авылга килгәндә аларда куна торган булган. Ничек сыйганнар? Хәер, бабам Азат хәтерләвенчә, 4-5 метрга 4-5 метрлы өйдә дүрттән бер өлешен мич алып торса да, сугыштан соңгы илленче елларда буена агач карават буена скамья куеп, балалар караватка аркылы төзелеп ята торган булганнар. Кунак-мазар булганда идәнгә салам салып, йоклый торган булганнар. “Бик җылы була иде”, - дип мактана Азат бабай.

Сугыш елларында да табиблар тикшергәндә бет табылмагач, Галимә әбигә авылда “Чиста Галимә” дигән кушамат тагылган. Шуңа чекист Сәләхиев үз иткәндер инде аларны...

Галимә әби 1920 еллар ачлыгын Чура керәшеннәре аркасында исән калдык дисә, сугыш ачлыгын Күзмес авылы удмуртлары (арлары) булышлыгы белән ач булмадык, дип сөйләгән...

“Атагызны госпительдән кайткач ике ел эшләтмәдем. Башта култык таяклары белән йөрергә өйрәнде, аннан агач аяк ясап бирделәр, сугыштан соң Казанда протез юнәтеп кайттык. Казанга йөргәндә бер чечән хатыны миңа бакты да, үзең тырышсаң – булыр, ялкауласаң – бетәрсең дип әйтте. Азат улым, безне арттан этүче дә, кулдан яисә тартучы да юк. Эштән курыкмыйча батырып эшләсәң, кеше малына тимәсәң, Ходай җан биргәнгә юнь бир ул!”– ди торган булган Чиста Галимә әбиебез. Минемчә, ул бик хаклыдыр.

***Сәримә САБИТОВА,***
***5 Б сыйныфы укучысы.***